ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2020 Казан шәһәре № 12-4/кс-2020

«Водоканал-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Водоканал Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен, әлеге карар кушымтасына туры китереп, эчә торган суга һәм су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Водоканал-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 04.03.2020 № 12-4/кс-2020 карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Водоканал-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Тәртип саны | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Водоканал Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | |
| 1.1. | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 14,21 | 14,77 | 24,56 | 25,88 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 11,84 | 12,31 | 20,47 | 21,57 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге